| | |
|---|---|
| **ГЛАВА<br>СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11. 2024 ел. Иске –Тәрбит авылы №4

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Камыллы авылында
үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында .

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗР Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп ярашлы рәвештә карар бирәм:

1. 2024 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Камыллы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы жирле эһэмияттэге автомобиль юлларын тэзу, ремонтлау,карап тору;

“риза” “каршы”

3. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы В.Г. Тимофеев